ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ

ПРИКАЗ — БОЕРЫК

__01.03.2023___ Казан ш. № __15_

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында

«Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы федераль законны, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы карарын үтәү йөзеннән,

боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен (кушымтада бирелә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең «Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында» 2015 елның 13 апрелендәге 40 номерлы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

3. Хокукый эш һәм өлешле төзүне тикшереп тору идарәсенең юридик бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Башлык — В.А. Кудряшов

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең __01.03.2023__№__15__ боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе (алга таба – Инспекция) норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына, шулай ук Инспекция тарафыннан эшләнә торган Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү процедурасын һәм коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләрен исәпкә алуны билгели.

1.2. Коррупциягә каршы экспертиза «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертизаны тәэмин итүнең һәм аларны әзерләгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуның өстәмә гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 29 июнендәге ПУ-575 номерлы Указын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2017 елның 15 августындагы 580 номерлы карарлары, шулай ук әлеге Тәртип нигезендә уздырыла.

1.3. Коррупциягә каршы экспертизаның максаты булып норматив хокукый актларда һәм норматив хокукый актларның проектларында коррупциячел факторларны ачыклау һәм алга таба бетерү тора.

1.4. Коррупциягә каршы экспертиза көчен югалткан яки гамәлдән чыгарылган норматив-хокукый актларга карата үткәрелми.

## II. Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү

2.1. Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза Инспекциядә коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат тарафыннан үткәрелә (алга таба – вазыйфаи зат). Әлеге вазыйфаи зат шулай ук Инспекциядә коррупциягә каршы экспертизага кергән норматив хокукый актларны һәм норматив хокукый актлар проектларын исәпкә алу журналын (алга таба – Журнал) (әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта) алып бару өчен дә җаваплы булып тора.

Вазыйфаи зат Инспекция башлыгы тарафыннан билгеләнә.

2.2. Норматив хокукый актлар яки норматив хокукый актлар проектларын эшләгән структур бүлекчә (алга таба – документны эшләүче) аларны вазыйфаи затка коррупциягә каршы экспертизага җибәрә, бу хәл алар алынган көнне Журналда теркәлә.

2.3. Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү вакыты Журналда теркәлгәннән соң ун көннән артмый.

2.4. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча вазыйфаи зат тарафыннан бәяләмә әзерләнә һәм имзалана.

Коррупцияле факторлар булуы турында бәяләмәдә (әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта) коррупциягә каршы экспертиза үткәргәндә ачыкланган коррупциоген факторлар чагылдырыла һәм аларны бетерү ысуллары тәкъдим ителә.

Норматив хокукый актларда һәм норматив хокукый актларның проектларында коррупциячел факторлар булмаган очракта, коррупциячел факторларның булмавы турында бәяләмә (әлеге Тәртипкә 3 нче кушымта) ясала, ул эшләүчегә җибәрелә.

2.5. Әгәр экспертизага юнәлтелгән норматив хокукый акт проектында коррупциоген факторлар булмаса, документны эшләүче, коррупциоген факторлар булмавы турында бәяләмә алгач, кызыксынган структур бүлекчә җитәкчеләренең визалары белән норматив хокукый акт проектын имзалау өчен җитәкчегә җибәрә.

2.6. Әгәр норматив хокукый актта коррупцияле факторлар ачыкланса, документны эшләүче, бәяләмәне алгач, структура бүлекчәсе җитәкчесе белән килешү буенча, аңа үзгәрешләр кертү кирәклеге яки аны үз көчен югалткан дип тану турында карар кабул итә.

Документны эшләүче ачыкланган коррупциоген факторларны бетерү максатыннан өч көн эчендә үзгәрешләр кертү турында норматив хокукый акт проектын яки актны үз көчен югалткан дип тану турында проект әзерли һәм вазыйфаи затка коррупциягә каршы экспертизага җибәрә.

2.7. Әгәр экспертизага юнәлтелгән норматив хокукый акт проектында коррупциоген факторлар ачыкланса, документны эшләүче, коррупциоген факторлар булуы турында бәяләмәне алгач, өч көн эчендә барлык кимчелекләрне бетерергә һәм норматив хокукый актның камилләштерелгән проектын вазыйфаи затка кабат коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен җибәрергә тиеш.

2.8. Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына

коррупциягә каршы кабат экспертиза үткәрү вакыты өч көннән артмаска тиеш.

2.9. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре Журналда теркәлә.

## III. Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү

3.1. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза объектлары булып рәсми басылып чыккан Инспекциянең норматив актлары, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталында яки Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актларын аларга коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру һәм алар хакында иҗтимагый фикер алышу максатларында урнаштыру өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары норматив хокукый актлары проектларын аларга коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру һәм алар хакында иҗтимагый фикер алышу максатларында урнаштыру өчен бердәм төбәк интернет-порталында (алга таба – бердәм төбәк интернет-порталы) билгеләнгән мәгълүмат ресурсында (http://tatarstan.ru/regulation) урнаштырылган Инспекциянең норматив актлары проектлары, Министрлыкта эшләнгән актларның проектлары тора.

Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза дәүләт серен яисә конфиденциаль характердагы белешмәләрне тәшкил итүче белешмәләрне үз эченә алган норматив хокукый актларга, норматив хокукый актларның проектларына карата үткәрелми.

3.2. Норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен, документны эшләүче, норматив хокукый актлар проектларын әзерләгән көннән башлап эш көне дәвамында, норматив хокукый актлар проектларын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта һәм бердәм төбәк интернет-порталында урнаштыру өчен аларны вазыйфаи затка җибәрә.

3.3. Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасына закон чыгару инициативасы тәртибендә кертелә торган федераль законнар проектларына, Татарстан Республикасы законнары проектларына, Татарстан Республикасы Рәисе указлары проектларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен, вазыйфаи зат аларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта һәм бердәм төбәк интернет-порталында Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең мәнфәгатьле башкарма органнарына, башка органнарга һәм оешмаларга килештерү өчен юлланган эш көне дәвамында урнаштыра.

3.4. Инспекциянең норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен вазыйфаи зат аларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Инспекциянең рәсми сайтында һәм бердәм төбәк интернет-порталында Хокук эше һшм лешле төзелешне контрольдә тоту идарәсенең юридик бүлегенә карау өчен җибәрелгән көнгә туры килүче эш көне дәвамында урнаштыра.

3.5. Коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен норматив хокукый актлар проектларын урнаштырганда вазыйфаи зат эксперт бәяләмәләрен җибәрү өчен

адресны (шул исәптән электрон почта адресын), шулай ук коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрне кабул итә башлау һәм тәмамлау даталарын күрсәтә.

3.6. Норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү вакыты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм бердәм төбәк интернет-порталында урнаштырылган көннән алып биш эш көне тәшкил итә.

3.7. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү нәтиҗәләре буенча алынган бәяләмә (алга таба – бәяләмә) Инспекциянең документлар белән тәэмин итү һәм оештыру эше бүлеге тарафыннан кабул итү көненнән соңга калмыйча, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының ведомствоара электрон документлар әйләнеше бердәм системасында теркәлә.

3.8. Норматив хокукый актны, норматив хокукый акт проектын эшләүче, әлеге Тәртипнең 3.9 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш һәм аны теркәгән көннән 15 көн эчендә коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздырган юридик яисә физик затка мотивлаштырылган җавап җибәрә (бәяләмәдә ачыкланган коррупциоген факторлар турында мәгълүмат яки ачыкланган коррупциоген факторларны бетерү ысулы турында тәкъдимнәр булмаган очраклардан тыш), анда коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләрен исәпкә алу һәм (яки) норматив хокукый актта яки норматив хокукый акт проектында ачыкланган коррупциоген фактор белән килешмәү сәбәпләре чагылдырыла.

3.9. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча түбәндәге бәяләмәләр каралырга тиеш түгел:

норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру буенча экспертлар сыйфатында Россия Федерациясе Юстиция министрлыгында аккредитацияләнмәгән юридик затлар һәм физик затлар тарафыннан әзерләнгән;

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы раслаган формага туры килми торган.

3.10. Әлеге Тәртипнең 3.9 пунктындагы өченче абзацта күрсәтелгән очракта, Инспекция мондый бәяләмәне теркәгән көннән башлап 15 көн узганчы, сәбәпләрен күрсәтеп, кайтарып бирә.

3.11. Норматив хокукый акт проектына коррупциягә каршы, шул исәптән бәйсез, экспертиза уздырганда ачыкланган коррупциячел факторлар норматив хокукый акт проектын эшләп бетерү стадиясендә аны эшләүче зат тарафыннан бетерелә.

3.12. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәсендә әйтелгән искәрмәләрне бетергәннән соң һәм тәкъдимнәрне исәпкә алганнан соң, документларны эшләүче норматив хокукый акт проектын вазыйфаи затка, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча килгән нәтиҗәләрне теркәп, кабат карау өчен тәкъдим итә. Кабат карау өч көнлек чорда гамәлгә ашырыла.

3.13. Әгәр норматив хокукый актта коррупцияле факторлар ачыкланса, эшләүче норматив хокукый актка үзгәрешләр кертү яки аны бәяләмә теркәлгәннән

соң өч көн эчендә үз көчен югалткан дип тану буенча чаралар күрә.

3.14. Әзерләүче зат үзе тарафыннан әзерләнгән, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон инициативасы тәртибендә Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасына кертелә торган федераль законнарның проектларында, Татарстан Республикасы законнары проектларында, Татарстан Республикасы Рәисе указлары проектларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларында коррупциячел факторлар булуы турында таныклый торган коррупциягә каршы, шул исәптән бәйсез, экспертиза нәтиҗәләре белән ризалашмаган очракта, әзерләүче зат күрсәтелгән норматив хокукый актларның проектларын, коррупциягә каршы, шул исәптән бәйсез, экспертиза бәяләмәсен һәм үзенең ризалашмавын нигезләгән аңлатма язуын теркәп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Регламентында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карау өчен кертә.

## IV. Норматив хокукый актларның проектлары хакында иҗтимагый фикер алышу

4.1. Инспекциядә эшләнә торган норматив хокукый актларын проектлары турында иҗтимагый фикер алышуларны тәэмин итә.

4.2. Иҗтимагый фикер алышу максатларында норматив хокукый актларның проектлары Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектларын аларга коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру һәм алар хакында иҗтимагый фикер алышу өчен бердәм төбәк интернет-порталы итеп билгеләнгән Татарстан Республикасы Рәсми порталында (алга таба – Мәгълүмат ресурсы) (http://tatarstan.ru/regulation) урнаштырыла.

4.3. Гражданнарның хокукларына, ирегенә һәм бурычларына кагыла торган норматив хокукый актларның проектлары иҗтимагый фикер алышуны тәэмин итү өчен Мәгълүмат ресурсында урнаштырыла.

4.4. Иҗтимагый фикер алышу максатларында урнаштырылмый:

дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләре яки конфиденциаль холыклы белешмәләре булган норматив хокукый актларның проектлары;

актларны (аларның структур берәмлекләрен) көчен югалткан дип тану турында норматив хокукый актларның проектлары;

аларны әзерләү өчен Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры һәм аның урынбасарлары йөкләмәсендә билгеләнгән срок иҗтимагый фикер алышуның минималь срогыннан азрак (Мәгълүмат ресурсында урнаштыру көненнән соң биш эш көнненән азрак) булган норматив хокукый актларның проектлары;

Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренә яки чыгымнарына йогынты ясый торган норматив хокукый актларның проектлары, Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешен тәэмин итүгә бәйле норматив хокукый актларның проектлары;

дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларның проектлары;

террорчылыкка, шул исәптән террорчылыкны финанслауга, каршы көрәш

чараларын тормышка ашырганда дәүләт хакимияте органнарының эшчәнлеген оештыру, тәэмин итү һәм аларның үзара хезмәттәшлек мәсьәләләрен регламентлый торган норматив хокукый актларның проектлары;

Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын законнардагы үзгәрешләргә туры китерүгә юнәлдерелгән норматив хокукый актларның проектлары;

суд карарларын, прокурор йогынтысы актларын, контроль-хисап органнары күрсәтмәләрен тормышка ашыру максатларында әзерләнгән норматив хокукый актларның проектлары;

дәүләт функцияләре үтәүнең административ регламентлары һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары проектлары;

статистик күзәтү формаларын раслау турында норматив хокукый актларның проектлары;

Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының гамәлдә булуын туктатып тору турында норматив хокукый актларның проектлары.

4.5. Иҗтимагый фикер алышуны тәэмин итү өчен норматив хокукый актларның проектлары урнаштырылганда вазыйфаи зат тәкъдимнәрне һәм кисәтүләрне җибәрү өчен адресны (шул исәптән электрон почта адресын), шулай ук иҗтимагый фикер алышу срогының башлану һәм тәмамлану даталарын күрсәтә.

4.6. Норматив хокукый актларның проектлары хакында иҗтимагый фикер алышу срогы Мәгълүмат ресурсында урнаштырган көненнән башлап биш эш көненнән азрак була алмый.

4.7. Документны эшләүче тарафыннан иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре буенча норматив хокукый акт проектын өстәмә эшләү турында карар кабул ителгән очракта, өстәмә эшләнгән норматив хокукый акт проекты шулай ук иҗтимагый фикер алышу максатларында урнаштырыла.

4.8. Норматив хокукый актларның проектларын Мәгълүмат ресурсында урнаштыру Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру срогы, иҗтимагый фикер алышу срогы тәмамланганнан соң 30 көнлек срокта вазыйфаи зат коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру барышында ачыкланган коррупциячел факторлар, иҗтимагый фикер алышу барышында килгән тәкъдимнәр турында җыелма мәгълүматларны аларны карау нәтиҗәләрен чагылдырып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган форма буенча урнаштыра.

Татарстан Республикасы
Дәүләт төзелеш күзәтчелеге
инспекциясе норматив
хокукый актларына һәм
норматив хокукый актлары
проектларына коррупциягә
каршы экспертиза уздыру
тәртибенә 1 нче кушымта

Коррупциягә каршы экспертизага килгән норматив-хокукый актларны һәм норматив-хокукый актларның проектларын исәпкә алу дәфтәре

| № | Актның (акт проекты-ның) экспертизага килү датасы | Актны (акт проектын) эшләгән структур бүлекчәнең аталышы | Актның (акт проекты-ның) аталышы | Экспертизаны үткәрү вакыты | Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәсе | Структура бүлекчәсе белгече тарафыннан бәяләмәне алу датасы һәм аны имзалау |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибенә 2 нче кушымта

Коррупциячел факторлар булу турында бәяләмә

________________________________________________________________________

(норматив-хокукый актның яки норматив-хокукый акт проектының аталышы)

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе тарафыннан «Норматив-хокукый актларның һәм норматив-хокукый актларның проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Норматив-хокукый актларның һәм норматив-хокукый актларның проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында» 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары белән расланган Норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү методикасы нигезендә коррупциягә каршы экспертиза үткәрелде

________________________________________________________________________.

(норматив-хокукый актның яки норматив-хокукый<br>акт проектының атамасы)

анда коррупциячел факторларны ачыклау һәм алга таба аларны юкка чыгару максатында.

Тапшырылган

________________________________________________________________________

(норматив-хокукый актның яки норматив-хокукый акт проектының аталышы)

________________________________________________________________________.

коррупция факторлары ачыкланды _________________________________________

(коррупция факторларының төрләре күрсәтелә)

________________________________________________________________________.

Ачыкланган коррупциячел факторларны юкка чыгару максатларында түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

________________________________________________________________________.

(коррупциячел факторларны юкка чыгару ысулы күрсәтелә)

| ____________________ | ________ | ________________ | __________ |
|---|---|---|---|
| (вазыйфа аталышы) | (имза) | (инициаллар, фамилия) | (дата) |

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибенә 3 нче кушымта

Коррупциячел факторлар булмавы турында бәяләмә

______________________________________________________________
(норматив-хокукый актның яки норматив-хокукый акт проектының аталышы)

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе тарафыннан «Норматив-хокукый актларның һәм норматив-хокукый актларның проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Норматив-хокукый актларның һәм норматив-хокукый актларның проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында» 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары белән расланган Норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү методикасы нигезендә коррупциягә каршы экспертиза үткәрелде

______________________________________________________________
(норматив-хокукый актның яки норматив-хокукый акт проектының аталышы)
_______________________________________________________.
анда коррупциячел факторларны ачыклау һәм алга таба аларны юкка чыгару максатында.

Тапшырылган

______________________________________________________________
(норматив-хокукый актның яки норматив-хокукый акт проектының аталышы)
_______________________________________________________.
коррупциячел факторлар ачыкланмады

| | | | |
|---|---|---|---|
| _____________________ | __________ | _______________ | ___________ |
| (вазыйфа аталышы) | (имза) | (инициаллар, фамилия) | (дата) |